Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең
Сизнер авылында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» март 2024 ел. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең Сизнер торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 2023 елның 28 ноябрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең Сизнер торак пунктында гражданнар җыелышы №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче пункт түбәндәгечә расларга:

«2. Алынган акчаны түбәндәге эшне башкарып җирле әһәмияттәге проблемаларны чишү өчен кулланырга:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:

- Сизнер торак пунктының Совет урамындагы күпер һәм юлны ремонтлау.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Смәел авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Йосыпов